ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02.2017 Балык Бистәсе штп. № 17пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибе турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 349.5 статьясы , Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре, Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүматны урнаштыру тәртибен раслау хакында» 21.11.2016 ел, №860 карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык эш хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен (алга таба-Тәртип) 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2.Гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла торган Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре (алга таба – муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр) җитәкчеләренә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнарына, календарь елында, муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы

турында мәгълүматларны 2017 елдан башлап отчет елыннан соң килгән елның 20 мартына кадәр әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә билгеләнгән форма буенча тапшыруны тәэмин итәргә.

3.«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге»муниципаль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты башлыгы урынбасары (мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча) белән берлектә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы Д. Х. Гатиятовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның 01 февралендәге
17 номерлы карарына кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык эш хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибе**

1.Әлеге Тәртип гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты башкара торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының, календарь елына исәпләнә торган уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыру тәртибен (алга таба - тәртип, учреждениеләр, предприятиеләр) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгели.

– 2.Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат:

–  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла;

– тиешле учреждениеләрне, предприятиеләрне гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә куючы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге учреждениеләрнең, предприятиеләрнең рәсми сайтларында өстәмә рәвештә урнаштырыла ала;

– Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында, учреждение, предприятиеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында хисап елыннан соң килә торган елның 31 мартыннан да соңга калмыйча урнаштырыла;

– «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланучылар өчен уңайлы формада бәян ителергә тиеш.

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында һәм учреждениеләрнең, предприятиеләрнең рәсми сайтларында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиешле мәгълүмат составында учреждениенең яки предприятиенең тулы атамасы, җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының вазыйфасы, фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелә.

4.Әлеге Тәртипнең 1 һәм 3 пунктларында каралган мәгълүмат составында Тәртибнең 1 пунктында күрсәтелгән затларның яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирүче белешмәләрне, шулай ук дәүләт серенә яки конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән белешмәләрне күрсәтү тыела.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның 01 февралендәге
17 номерлы карарына кушымта №1

**Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты башкара торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының, календарь елына исәпләнә торган уртача айлык хезмәт хакы турында мәгълүмат урнаштыру формасы**

---

Отчёт чоры _______ ел

| № п/п | Вазифа | ФИО (тулысынча) | Уртача айлык хезмәт хакы күләме, сум |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Мәгълүматның дөреслеген раслыйм:

________________________ М.П. ________________________

(имза) (дата)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениесе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиесе җитәкче вазифасының исеме